**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

№2 30 октябрь 2025 ел.

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Югары Баланда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35статьясы ,Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Югары Баланда авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Югары Баланда авылы, Овражная урамы, 5 нче йорт янында.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Югары Баланда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә таләпләр, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Баланда авылы территориясендәге үсентеләрне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).
- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) Югары Баланда авылы).

**Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Югары Баланда авылында

тирәнлек насосын ремонтлау һәм алмаштыру, сууткәргечне ремонтлау (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга .

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы: С.С.Елисеев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
р 06-3752/13
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРИВООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1603004871 ОГРН 1061665002519